Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының егерменче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

20 сентябрь, 2019 ел № 133

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Питрәч авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге карар чыгарды:

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә «2020 елда 18 яшькә җиткән, 1 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, мәктәп укучыларыннан кала, аның яшәү урыны Питрәч авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, Россия Федерациясенең һәр гражданиныннан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» дигән тәкъдим белән чыгарга:

- Питрәч авылында тротуарлар төзү;
- Олан Иле авылында балалар мәйданчыгы төзү;
- Шихазда авылы эчендәге юлларны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Питрәч авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) халыкка хәбәр итәргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000909